**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Югары Шубан авыл җирлегенең Түбән  Шубан торак пунктында 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү турында**

**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**2025 елның 25 ноябре.** **№2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45 һәм 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Югары Шубан авыл җирлегенең Түбән Шубан авылында **халык җыены карар бирә**:

1. Россия Федерациясе кораллы көчләренә мобилизацияләнгән гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына узарасалымның 90% һәм 50% күләмендә ташлама билгеләнгән 1 төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, 90 яшьтән өлкәнрәкләрдән, авырып ялгыз яшәгән өлкән пенсионерлардан һәм тыл хезмәтчәннәреннән кала, Шубан авыл җирлегенен Түбән Шубан авылында теркәлгән,балигъ булган һәр гражданга 2026 елда узарасалымны 600 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирлектә әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Түбән Шубан авылы Г.Тукай урамы буенча вак таш түшәлгән юлларны  норматив хәлгә китерү);
- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (балалар уен мәйданчыгын ремонтлау).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шубан авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга, http:// pravo.tatarstan.ru. Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән  халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Муниципаль берәмлек башлыгы,
Совет Рәисе: С.З.Васильева